**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА МАСАДИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423753, деревня Масады,
ул. Нефтяников ,дом 18 ,
Тел. 3-44-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ МЭСЭДЕ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
423753, Мэсэде авылы,
Нефтяниклар ур.,18 нче йорт.
Тел. 3-44-49

**№ 1** **09.11.2019**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлегенең Мәсәде,Бурсык торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Мәсәде авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Мәсәде авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 20 ноябренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2020 елда Актаныш муниципаль районының Мәсәде авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү,көндезге бүлектә укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан тыш, бирелгән акчаларны түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Масады, Бурсык авылларында юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС салу, грейдлау,кардан чистарту).

Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- янгын сүндерү өчен су цистернасы алу;

-авыл җирлегенең ташландык участокларын чистарту, куаклар һәм агачлар кисү, объектларны сүтү һәм участокларны тоту;

Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру.

Халыкка торак-коммуналь, көнкүреш һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә эш оештыру:

- урам яктырткычларын һәм электр челтәрләрен карау.

Җирлек халкына  массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү:

- рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру.

« ӘЙЕ»          «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Мәсәде авылы, Нефтьчеләр ур., 18 йорт.

4.Халык җыенын Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра.

5. Мәсәде авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында әлеге карарны халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Мәсәде
авыл җирлеге башлыгы:                Ф.Р.Минһаҗетдинова